**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.04.2017 Балык Бистәсе штп. № 84пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 72 еллыгына әзерлек һәм бәйрәм итү турында» 2016 елның 28 мартындагы 56пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 72 еллыгын бәйрәм итү уңаеннан тантаналы чара үткәрү һәм 2017 елның 9 маенда Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогында терроризм актларын кисәтү һәм җәмәгать куркынычсызлыгын көчәйтү максатларында, «Терроризмга каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 72 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү турында» 2016 елның 28 мартындагы 56пи номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) преамбулда «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 24 мартындагы 555-р номерлы күрсәтмәсе» сүзләрен «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 72 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү турында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 24 мартындагы 555-р номерлы күрсәтмәсе» сүзләренә алмаштырырга;

1.2) 3 пунктта «Татарстан Республикасы хәрби комиссариатының Балык Бистәсе районындагы бүлеге» сүзләрен «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы хәрби комиссариаты " сүзләренә алмаштырырга»;

1.3) 5 пунктта "Татмедиа" ААҖ филиалы "Авыл офыклары" газетасы редакциясе» сүзләрен «Татмедиа" АҖ филиалы"Сельские горизонты"("Авыл офыклары") газетасы редакциясенә» сүзләренә алмаштырырга;

1.4) түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге башкарма комитетына, Россия Эчке эшләр

министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлегенең юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе бүлеге (килешү буенча) белән берлектә, 2017 елның 9 маенда сәгать 9.00 дән 12.00 гә кадәр Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогында Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 72 еллыгына багышланган тантаналы чара үткәрү чорында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының тиешле участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча туктатуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә »;

1.5) 6 пунктны 7 пункт дип санарга .

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин